ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» 540-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» 540-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2396-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Л.А. Якунин тарафыннан кертелә

**«Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге закон Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә региональ салымнар суммалары өлешендә бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгели.

2 статья. **Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр**

2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә исәпләнелә торган, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләнү мөмкин булмаган региональ салымнар суммалары өлешендәге бурыч түләнүгә ышанычсыз дип таныла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган региональ салымнар буенча оешмаларга яисә индивидуаль эшкуарларга исәпләнелә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

3 статья. **Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар**

Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) вафат булуга бәйле рәвештә, физик затны салым органнарында исәптән алу хакындагы белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы хакында оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, датасы, номеры);

3) әлеге Законның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда – 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу хакында салым органы белешмәсе.

4 статья. **«Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын үз көчен югалткан дип тану**

«Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2017 елның 19 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләнә ала.

Әлеге вәкаләтләр «Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2017 елның 19 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – Закон) кабул итү юлы белән гамәлгә ашырылды.

Шуның белән бергә, Законны мониторинглау, шулай ук хокук куллану тәҗрибәсен анализлау нәтиҗәсендә андагы хокукый нормаларны камилләштерү һәм актуальләштерү кирәклеге ачыкланды.

Шуңа бәйле рәвештә «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты эшләнде.

Закон проекты белән бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану датасы итеп 2024 елның 1 гыйнварын билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проектында региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга түбәндәге нигезләр күздә тотыла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган региональ салымнар буенча оешмаларга яисә индивидуаль эшкуарларга исәпләнелә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

Шулай ук региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар исемлеге билгеләнә.

Гамәлдәге Закон үз көчен югалткан дип таныла.

Салым органнары мәгълүматы нигезендә әлеге нигезләр буенча бурычны бетерү суммасы 16,2 мең бурычлыдан якынча 20 млн сум дип бәяләнә.

**«Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматы нигезендә региональ салымнар буенча бурычны бетерү суммасы якынча 20 млн сум күләмендә бәяләнә.